Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Иске Чаллы авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«18» ноябрь 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Иске Чаллы авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Иске Чаллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидларыннан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1). Иске Чаллы торак пункты чикләрендәге юлларны ремонтлау;

2). Авыл хуҗалыгы техникасына тагылмалы җиһазлар сатып алу.

Халык җыены рәисе: И.Н. Захаров

Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Захаров